| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2025 г.Казань № 135-6/т-2025

2026 елга Түбән Кама шәһәренең «Нефть химиясе транспорт компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан килә торган тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тариф билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.06.2023 ел, № 70-1/т-2023 карары белән расланган Татарстан Республикасында сәнәгать тимер юл транспорты оешмалары һәм башка хуҗалык субъектлары тарафыннан керә торган тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә тарифлар билгеләү тәртибе, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 27.08.2025 ел, №14-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә Түбән Кама шәһәренең «Нефть химиясе транспорт компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан подъезд тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән иң чик максималь тариф 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В.Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.08.2025 № 135-6/т-2025
карарына кушымта

Түбән Кама шәһәренең «Нефть химиясе транспорт компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан килә торган тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә 2026 елга максималь дәрәҗәдә чик тариф

I бүлек. Чик дәрәҗәдә максималь тариф

| т/с | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Чик дәрәҗәдә максималь тариф, сумнарда (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | 1 км ераклыкка йөк алып бару | 1 тонна | 42,64 |

II бүлек. Башка шартлар

1. Сәнәгать тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган, әмма «Чик дәрәҗәдә максималь тариф» дигән I бүлектә каралмаган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар яклар килешүендә, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Сәнәгать тимер юл транспортында башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар һәм җыемнар формалаштыру буенча методик күрсәтмәләр нигезендә билгеләнә.

2. Йөк ташу һәм төяп җибәрү-бушату эшләре өчен түләү заказчыдан ташылган йөкнең фактик авырлыгы өчен алына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге